**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(бишенче чакырылыш)**

# КАРАР
**Алтынчы утырыш**

**04 май 2026 ел.** **№ 17** **Олы Мәтәскә авылы**

**«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен «Татарстан Республикасы Теләче муниципальрайонының Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турында**

«Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлыФедеральзаконның 11 статьясынигезендә,«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2026 елның 26 мартындагы 40 номерлы карары белән, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының фикерен белдереп, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турында инициативасын кушымта итеп бирелгән карта-схема нигезендә хупларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында һәм Олы Мәтәскә авыл җирлегенең рәсми стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә: ТР, Теләче районы, Олы Мәтәскә авылы, Фатыйх Хөсни ур., 56А йорт, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә, Центральная ур., 17а йорт, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Лесной пос.,Татарстан ур., 8 йорт,

Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Ямбулат авылы, Татарстан ур., 18 йорт, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Тәмти Мәтәскә авылы, Подгорная ур., 15 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Олы Мәтәскә авыл җирлеге башлыгы Ш. В. Кәримуллин

Кушымта
Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл
җирлеге Советының 2026 елның 4 маендагы 17
номерлы карарына

## Карта-схема муниципальных образований с учетом изменений

